| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**БАКРЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ТӘТЕШ**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**БАКЫРЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

тел. (84373) 50-2-35, факс 50-2-35

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.11.2020** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында, гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыенын билгеләү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, “Татарстан Республиксында җирле үзидарәләр турында”гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Бакырчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә **КАРАР КЫЛАМ:**

1. 2020 елның 19 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында түбәндәге адрес буенча урнашкан Бакырчы авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 1 этабын үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Бакырчы авылы, Вахитов урамы, 9 нчы А йорт.

2. 2020 елның 19 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында түбәндәге адрес буенча урнашкан Бакырчы авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының 2 этабын үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Бакырчы авылы, Вахитов урамы, 9 нчы А йорт.

3. Вакытлы билгеләр буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибе.

4. Гражданнар җыенында тәкъдим ителүче мәсьәләне раслау:

“Сез, 2021 елга түбәндәге:

- Зират территориясен әйләндереп алган койманы ремонтлау(төзелеш материаллары сатып алу);
- Бакырчы торак пунктындагы Вахитов һәм Тукай урамнарындагы авыл эче юлларын ремонтлау;
- Бакырчы торак пунктындагы кизләүнең территориясен төзекләндерү эшләрен

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан кала, Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелырга ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлеге**
**Башлыгы** **И.М. Шәмсетдинов**